КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 сентябрь г.Казань № 1050

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 15 июнь, 564 нче карары белән расланган Гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яки берләштерелгән лицензия буенча аларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен, эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару өчен яки җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен, коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яки) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын чыгару өчен, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен файдалануга бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау

һәм чыгару өчен яки берләштерелгән лицензия буенча аларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен, эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару өчен яки җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен, коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яки) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын чыгару өчен, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен файдалануга бирү тәртибе» 2022 ел, 15 июнь, 564 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 18 август, 855 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яки берләштерелгән лицензия буенча аларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен, эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару өчен яки җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен, коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яки) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын чыгару өчен, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен файдалануга бирү тәртибенә, 3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.3. Аукционда катнашу турындагы заявкаларны Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән юридик затлар, Россия Федерациясе гражданнары булган индивидуаль эшмәкәрләр (алга таба – заявка бирүчеләр), әгәр дә федераль законнар белән башкасы билгеләнмәгән булса, бирергә хокуклы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин